# Нократ

Район яңалыклары безнең сайтта **www.mamadysh-rt.ru** һәм социаль челтәрләрдә

№42 (11904) 25 октябрь 2024

Мамадыш муниципаль районы газетасы 1918нче елның 6нчы февраленнән чыга

16+


# Сәламәт кешеләргә үрнәк ул

Махсус хәрби операциядә бер аягын югалтса да, ул күңелен төшерми.



Игорь Киселев (рәсемдә уртада) данлыклы хоккейчылар Вячеслав Фетисов (уңда) һәм Кирилл Капризов (сулда) белән Александр Овечкин кубогы ярышларында очраша. Фото шәхси архивтан.

3 бит

## БҮГЕНГЕ САНДА

**РЕСПУБЛИКА РӘИСЕ ЮГАРЫ БӘЯЛӘДЕ:** район башлыгы Вадим Никитин ТР Хөкүмәте йортында агымдагы елда башкарылган эшләр турында чыгыш ясады.



6-7 битләр

**"БУ ЯШЬ ҮЗЕМӘ БИК ОШЫЙ":** һаман да җитез, елгыр, юморга бай Марат Баязитовка 70 яшь тулуына ышанасы килми.



8 бит

Иң җитез яңалыклар!





podpiska.pochta.ru

# Эшкә урнашу өчен кешенең яше комачау түгел

## Соңгы елларда хезмәт базарында зур үзгәрешләр күзәтелә.

**Эшче көчләрнең читкә китүе аркасында күп кенә оешмаларда, учреждениеләрдә кадрлар кытлыгы беркем өчен дә сер түгел. Җитәкчеләр бу проблеманы пенсионерлар хисабына яисә хезмәткәрләрен башка һөнәрләргә яңадан укыту һ.б. аша хәл итәргә тырышсалар да, шул ук вакытта күпчелек гаять зур кыенлык кичерәләр. Килеп туган әлеге хәлләрдән чыгу юллары турында Мамадышның халыкны эш белән тәэмин итү үзәге җитәкчесе ЛӘЙЛӘ ХӨСНЕТДИНОВА белән сөйләштек.**

**– Ләйлә Рәфисовна, хезмәт базарындагы бүгенге вәзгыять турында сөйләгез әле.**

– Татарстан Республикасы буенча 2024 елның башыннан алып 1 сентябренә 3572 эшсез, 53246 буш вакансия теркәлгән. Мамадыш районында исә - 37 эшсез һәм 151 вакансия, асылда бер эшсез гражданинга 4 вакансия туры килә. Безнең районда эшсезлек дәрәҗәсе 0,19%, бу түбән күрсәткеч. Бездә исәптә күбесенчә пенсия алды яшендәге кешеләр тора. Быелның башыннан 1 сентябренә кадәр мәшгульлек үзәгенә 212 кеше мөрәҗәгать иткән, 171 кеше эшкә урнаштырылган. Нигездә, районның бюджет учреждениеләренә кадрлар җитми. Минемчә, аз хезмәт хакы аркасында күпләргә Алабугадагы ирекле икътисадый зона вакансияләре кызыклы. Мисал өчен, хәзерге көндә Мамадыш үзәк район хастаханәсендә 20, сыр заводында - 57, Татавтодорда - 27 буш вакансия бар. Шунысы куанычлы, Алабуга заводларына киткән мамадышлыларның күбесе «Вятка» сәнәгать паркына кире кайта башлады. Чөнки эш урынының яшәгән җиргә якында булуы да, югары хезмәт хакы да үз эшен эшли.

**– Эшкә урнашканда социаль контракттан хәзер дә файдаланып буламы?**

– Әлбәттә. Моның өчен эшкә урнашучы кешегә социаль яклау бүлегенә гариза белән мөрәҗәгать итәргә яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы» системасы, яисә МФЦ аша электрон гариза бирергә кирәк. Нәтиҗәдә, барлык критерийларга туры килгән очракта, кеше 4 ай дәвамында хезмәт хакыннан тыш 14 317 сум акча алачак, бу гаилә өчен яхшы ярдәм булып тора, дип саныйм. Әлеге мөмкинлек турында тулырак газета укучылар районыбызның халыкны социаль яклау бүлегендә белә алалар.

**– Хәзер уртача хезмәт хаклары нинди?**




**Мамадыш шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең исеме үзгәртелде. Хәзер ул Мамадыш районы буенча «ТР Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ бүлеге дип атала. Әлеге үзгәртеп кору "Работа России" бердәм стиле кысаларында хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәлелеген күтәрергә мөмкинлек бирәчәк. Яңалык "Демография" милли проектын гамәлгә ашыру кысаларында бара.**

- Республикабыз буенча уртача хезмәт хакы - 69 604 сум, Мамадыш районында - 60 мең сум. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, бездә бу күрсәткеч нигездә “Родные Места” Компанияләр төркеме предприятиеләре хисабына барлыкка килә, андагы күпсанлы хезмәткәрләргә шул суммадан да ким түләнми. Әйтергә кирәк, агрохолдинг авыл хуҗалыгы буенча белем бирә торган урта һәм югары уку йортларын тәмамлаучылар белән актив эшли, хәтта студентларга исемле стипендияләр түли, яшь белгечләргә торак бирә һәм шуның белән кадрлар мәсьәләсен уңышлы хәл итүче районыбызда бердәнбер предприятие санала.

**– Яңа кадрлар җәлеп итү буенча нинди чаралар, акцияләр, программалар бар?**

- Кадрлар әзерләү бездә мәктәп эскәмиясеннән башлана. Мәгариф бүлеге белән тыгыз эш алып барабыз. Мамадыш мәктәпләрендә 2008 елдан гамәлгә кертелгән "Тормыш дәресләре” укучыларга район предприятиеләре, “Вятка” сәнәгать мәйданчыгы белән танышырга мөмкинлек бирә, ә экскурсияләр, хезмәт династияләре, алдынгылар белән очрашулар мәктәп укучыларының һөнәр сайлаудагы фикерләрен нык үзгәртә. Ә безнең төп кадрлар потенциалы - Мамадыш политехник көллиятен тәмамлаучылар. Алар безнең алтын фондыбыз. Әлеге уку йортын тәмамлаучыларның күбесе районыбыз һәм республика предприятиеләренә һәм оешмаларына эшкә урнаша. Эшче һөнәрләренең абруе арту бик сөендерә. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, көллият җитәкчелеге хәзерге заманда актуаль булган яңа укыту юнәлешләрен даими ача. Моның өчен аларга зур рәхмәт. Чираттагы вакансияләр ярминкәсен без октябрь аенда нәкъ менә көллият базасында уздырырга планлаштырабыз, анда студентлар эш бирүчеләргә һәм район җитәкчелегенә турыдан-туры сораулар биреп, үзләре өчен кирәкле вакансияләр таба алачак.

**– “Демография” милли проектын гамәлгә ашыру ничек бара?**

–Безнең районда әлеге илкүләм проект бирә торган мөмкинлекләрдән күп кенә мамадышлылар файдаланды инде. Ул яңа һөнәргә бушлай укырга мөмкинлек бирә, «Работа России» порталы аша гамәлгә ашырыла. Мисал өчен, кеше бухгалтер булып эшли ди, аңа җитәкчесе ярты ставка кадрлар бүлеге хезмәткәре вазыйфасын тәкъдим итә. Ул югарыда аталган портал аша гариза бирә, аннары без аны эшкәртәбез, профориентация буенча тест үткәрәбез. Нәтиҗәдә эш бирүче, уку йорты һәм мөрәҗәгать итүче белән өч яклы килешү төзелә. Һәм кеше бушлай онлайн рәвештә яңа һөнәргә укый. Бу бик уңайлы һәм ифрат та отышлы чара. «Демография» милли проекты 2019 елдан бирле эшләп килә.

**– 5-10 ел элек белән чагыштырганда хезмәт базары нык үзгәрдеме?**

–Үзгәрешләр җир белән күк арасы, дияр идем. 5-10 ел элек 45 яшьтән узган кешеләр хезмәт категориясенә керми иде, ә хәзер эш тәкъдим итүчеләр 60 яшьтән өлкәнрәк кешеләрне дә, ягъни пенсия алды яшендәгеләрне дә эшкә алырга әзер. Бюджет учреждениеләрендә машина йөртүчеләр булып нигездә пенсионерлар эшли. Шулай булгач, кешенең яше эшкә урнашу өчен һич тә комачау түгел.

**–Сезнең фикерегезчә, бюджет учреждениеләрендә кадрлар мәсьәләсен ни рәвешле уңай хәл итеп була?**

–Мәгариф, мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт хаклары сизелерлек артмаса, тенденция элеккечә калачак, дип саныйм. Табибларга түләүләрне арттыргач, яшьләр Мамадыш үзәк район хастаханәсенә кайта башлады бит. Киләсе елдан МРОТ 22440 сумга җитәчәк. Бу бюджет өлкәсендә хезмәт хаклары арта башлаячак, дигән өмет уята.

**–Әңгәмә өчен рәхмәт.**

**Әңгәмәдәш - Фәүзия Нургалимова.**

**Темага**

Мамадыш районында эш урыннары, шулай ук уздырыла торган вакансияләр ярминкәләре белән сез монда таныша аласыз:
–"Россия Эше» порталы;
– Мамадыш районы ЦЗН ДКУ мини-сайты ;
–ВКда "Есть Контакт" төркеме



Мамадыш шәһәре башкарма комитетының җитәкчесе Рәшит Гарипов (алгы планда) Дачный бистәсенең үсеш планнары турында сөйли. Алмаз Камалеев фотосы.

# Күп балалыларга - җирләр бирелде

**Мамадышта күп балалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бүлеп бирелде. Гариза язган 85 кеше катнашындагы җыелыш район Советы һәм башкарма комитетының утырышлар залында узды.**

Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Рәшит Гарипов Дачный микрорайонының инфраструктура үсеше перспективалары һәм этаплары турында сөйләде. Территорияне газлаштыру проекты эшләнгән, бу эш 2025 елда башланачак. Су белән тәэминителеш соңрак булачак, юллар да микрорайонга барлык инженерлык коммуникацияләре кергәч кенә салына башлаячак.

Хәер, бу вәзгыять беркемне дә куркытырга тиеш түгел. Күбебез белә, моннан берничә ел элек яшь гаиләләр тарафыннан актив үзләштерелгән Төньяк һәм Төньяк 2 бистәләрендә дә башта проблемалар күп иде. Бүген исә бу микрорайон үз мәктәбе, балалар бакчасы, спорт объектлары булган шәһәребезнең иң ямьле урыннарының берсе санала.

Дачный бистәсе Мамадышның көньягында урнашкан. Мәгасумов, Сорокин, Мәмдәш һәм башка патриотик исемнәр бирелгән урамнарда яшәячәк кешеләр йортларын Нократ елгасы күренә торган, матур урыннарда салуны планлаштыра алалар.

Исегезгә төшерәбез, дәүләт инициативасы гамәлгә кергәннән алып, Мамадыш районында 1026 бушлай җир кишәрлеге бирелде. Беренче гаризаларны 2011 елда кабул иткәннәр иде. Күп балалы гаиләгә җир кишәрлеген түләүсез бирү турында исемлекләр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы оешмасы тарафыннан төзелә.


Лена Бачкованы бүләкләү мизгеле.

# Елена Бачкова: "Укытучы һөнәре матур итеп киенеп йөрү генә түгел"

Бел безнекеләрне!

Алинә **Галимҗанова**

**Владимир авылы мәктәбе директоры Елена Бачковага "Россия Федерациясенең мактаулы мәгариф өлкәсе хезмәткәре" исеме бирелде. Елена Алексеевна, 1984 елда мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан Дәүләт институтының химия-биология фәннәре укытучысы белгечлеге алырга дип шәһәргә китә.**

– Без укыган чорда укытучы һөнәре бик зур хөрмәткә ия иде, шуңа күрә, институтта 1 урынга 7-8 кеше туры килде. 4 имтихан бирергә кирәк иде, бер фәннән бишле билгесенә бары тик 1 балл җитми калды, шуңа күрә ул елны укырга кереп булмады. Югалып калмадым, үз укытучыларым янына, Мамадыш районының Албай урта мәктәбенә өлкән пионервожатый булып урнаштым. Үземне укыткан остазлар белән берррәттән 1 ел эшләп чыктым. Шушы 1 ел эчендә укытучы һөнәре матур итеп киенеп йөрү түгел, ә бик авыр һәм җаваплы эш икәнен аңладым, – дип сөйләде Елена Бачкова.

Елена Алексеевна шушы 1 ел эчендә артка чигенмәгән, киресенчә, имтихан бирәсе фәннәрне тагын да яхшырак өйрәнеп, яңадан укырга керергә барган. Шулай итеп, бөтен фәннәрне бишлегә тапшырып, ул үзе теләгән уку йортына кереп, хыялланганча, укытучы белгечлегенә төшенә башлый.

– Бик тырышып белем алдым, ай саен 50 сум стипендия килә иде. Укуга бик җитди карадым, авылга да елына 4-5 тапкыр гына кайтып булды, тырышып укыган кешегә белем алу җиңел бирелми ул. Укып бетергәннән соң Түбән Сон авылында химия-биология укыта башларга тиеш идем, шул вакытларда булачак ирем Николай Бачков белән таныштым, ул Владимир авылы егете, үз авылларына кайтырга өндәде. Шулай итеп, мин Владимир авылында укыта башладым. Николайга кияүгә чыктым. Ул баянист, мин активист дигәндәй, бөтен әйберне бергә алып бара идек, – диде Елена Алексеевна.

**Бер ел эшләгәннән соң, Елена Алексеевна завуч була, ә 2001 елдан ул директор вазыйфасын үти. Соңрак ире Николай Петрович та шушы мәктәпкә укытырга кайта. «Гомер буе бу йөкне бергәләп тарттык» ди Елена Алексеевна.**

–Җитәкче буларак, һәрвакыт беренче планга башкалар турында кайгыртуны, үз хезмәттәшләрем, укучыларымның мәнфәгатьләрен куйдым. Бар эштә башкалар фикерен тыңлап, уртага салып, киңәшләшеп, коллективым ярдәменә таянып эш иттем. Тик нинди генә эш булмасын, башлап җибәрүчесе үзем, калганнар иярде. Уку-укыту, тәрбия процессында да, җәмәгать эшләрендә дә. Бер йодрык булып, бергә шатлыкларны да бүлешәбез, авыр чакларда да ярдәмләшеп яшибез. Миңа бирелгән «Россия Федерациясенең мактаулы мәгариф өлкәсе хезмәткәре» исеме дә безнең уртак эшебез нәтиҗәсе, – дип сөйләде Елена Бачкова.

**"Туганайлар" газетасыннан алынды.**

Актуаль

Николай **Михайлов**

# Бәяләр артты, ләкин чаң сугарлыкмы?

**"Мәктәптә туклану" сүзтезмәсе эчендә балаларыбызның сәламәтлеге ята. Шуңа күрә өйдә генә түгел, мәктәпләрдә дә, санитар нормаларга туры китереп, туклануны дөрес оештыру – укучыларның сәламәтлеген саклауда мөһим фактор булып тора һәм белем алу сыйфатына да зур йогынты ясый.**

Мәгълүм булганча, башлангыч сыйныф укучылары мәктәпләрдә бушлай тукланалар. Моның өчен федераль бюджеттан һәр балага бер тапкыр ашатуга 66,76 сум акча каралган. Яңа елдан соң әлеге сумма артачак, дип белдерделәр район мәгариф бүлегендә. Ә 5-11нче сыйныфларда белем алучыларның ата-аналарыннан моңарчы 25әр сум җыялар иде. Яңа уку елыннан әлеге сумма 15 сумга артты. Ашатуга киткән чыгымнарның калган 9,20 сумы субсидияләнә. Яңа елдан соң аның күләме артыр дип көтелә. Шулай итеп, бер баланы көнгә бер тапкыр ашату 49,20 сумга төшә. Дөрес, бу сумма барлык эти-әниләргә дә кагылмый. Белем бирү учреждениеләрендә өч баласы белем алган ата-аналар һәр бала өчен 35әр сум гына түлиләр. Калган сумманы, ягъни 5 сумны, район бюджеты каплый. Әгәр инде гаиләдә дүрт һәм аннан да күбрәк укучы бала булса, алар мәктәпләр ашханәләрендә бушлай тукланалар. Бу категориягә ведомстводан тыш саклау һәм эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең 50гә якын баласы да керә. Әтиләре һәм бертуган абыйлары махсус хәрби операциядә катнашучы кызлар һәм малайларга да бушлай туклану каралган. Бу категориягә районыбызда 70ләп укучы керә. Озайтылган көн төркемнәренә йөрүче (андыйлар 400ләп) һәм сәламәтлекләре чикләнгән балалар (10 укучы), шәһәрдәге 2нче санлы лицейның – хоккей, шәһәрдәге 4нче санлы урта гомуми мәктәпнең кадет классларында белем алучы 300 чамасы укучы көнгә ике мәртәбә кайнар аш белән тәэмин ителәләр. Беренчеикенче категориягә кергән һәр балага икенче тапкыр ашату өчен бюджеттан – 12,38, яшь хоккейчыларга һәм кадетларга 17,78 сум акча каралган. Беренче тапкыр тукланган өчен югарыда телгә алынган сумма тотыла.


"Иң тәмлесе – бәрәңге боламыгы белән кәтлит",– диләр шәһәребезнең өченче санлы урта гомумбелем бирү мәктәбе укучылары. Наталья Клинова фотосы

Мәктәп ашханәләрен ризыклар белән тәэмин итү белән "Нократ" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять шөгыльләнәчәк. Ит ашамлыклары "Родные Места" Компанияләр төркеменеке, ипи "Г.М.Хәсәнова" ИПныкы, сөт продуктлары Яшел Үзәннән кайтартыла. Җиләкҗимешләр, яшелчәләр белән проблемалар юк. Чөнки аларны белем бирү учреждениеләре үзләренең участокларында кышка җитәрлек әзерлиләр.

# Идел буйлап сәяхәт

Район газетасы редакциясе коллективы Свияжск утрау-шәһәрчегендә булып кайтты.

Күңелле булды

Фәүзия **Нургалимова**

**Анда без онытылмас мизгелләр алу бәхетенә ирештек.**

Редакциядә шундый күркәм гадәт бар – ел саен коллектив белән республикабызның моңарчы без аяк басмаган төрле почмакларына сәяхәт итү. Юлга кузгалыр алдыннан һәркайсыбызның фикере, теләге исәпкә алына: кемдер башкалабыз Казандагы театрларга барырга теләк белдерә, икенче берәүләрнең ял базасында ял итәсе килә. Бу юлы җитәкчебез Светлана Ханованың Идел буйлап су трамваенда сәяхәт итәргә дигән тәкъдименә беребез дә каршы килмәдек. Барыбыз бу идеяне күтәреп алдык һәм сәяхәткә чыгасы көнне зур түземсезлек белән көтә башладык.

Казанның елга портына кадәр район мәгариф бүлеге биргән кечкенә автобуста бардык. Техника өчен бүлеккә рәхмәтлебез. Водитель Мөнир Мостафин безне билгеләнгән урынга иртәнге сәгать 9га алып килеп җиткерде һәм сабыр гына 16.00 сәгатькә кадәр шунда көтеп утырды.

Елга портына килеп җитүгә хозурыбызга җәйрәп яткан Идел килеп басты, портта күпсанлы суднолар швартовкага тезелгәннәр иде: теплоходлар, су трамвайлары, катерлар. Көн җәйге кебек кояшлы, җылы иде. “Василий Суриков” исемле зур теплоход янында фотога төшкәннән соң, карап торышка кечкенә күренгән “Троттер” трамваена таба киттек. Урындыкларга уңайлы гына урнашып, су өстендәге дулкыннарга, күз явын алырдай ярларга хозурланып, Иделдәге суднолар йөреше, Свияжск утравы белән бәйле тарихлар турындагы аудиоязманы тыңлап, киң елга буйлап йөзеп киттек.

Свияжскка Иван Грозный заманында, рус гаскәрләре Казанны берничә мәртәбә алырга омтылган чорларда нигез салына. Утрау рус патшасы өчен ныгытылган хәрби базага әверелә. Шуның нәтиҗәсендә Казан шәһәре алына да инде. Свияжск үз тарихында күп кенә танылган шәхесләрне әле дә хәтерли. Патша җәберенә дучар булган Меньшиков сөргенгә барганда хатынын биредә күмә. Монда патшабикә Екатерина Икенче, патшалар Павел Беренче һәм Александр Икенче тукталыш ясыйлар. Утрау Пушкинга аеруча ошаган! Ул аны чын Буян утравына тиңләгән.

Ике сәгатькә сузылган вакыт эчендә су буйлап барганда без утрау турында күп кенә кызыклы тарихлар тыңладык. Аңа килеп җиткәч, боларның барысын да үз күзләребез белән күрергә насыйп булды. Свияжск пристанендә зур булмаган берничә судно тукталган иде инде. Димәк, биредә туристларның өзелеп торганы юк. Безне экскурсовод Гөлфия Мишина каршы алды. Тумышы белән ул шушы шәһәрчектән, гомере буе җирле мәктәптә балаларга рус теле һәм әдәбияты укыткан. Хәзер исә туристларны Свияжск шәһәрчеге тарихы белән таныштыра. Аны рәхәтләнеп тыңладык. Чөнки ул утрауда үзе шаһит булган тарихи вакыйгалар турында да сөйләде. Без Успенский монастырендә булдык. Ул 1918нче елдан соң психик яктан авырулар өчен хастаханәгә әверелә. Дингә ышанучыларга әлеге иман йортын яңадан үзләренә кайтару өчен 90 ел вакыт кирәк була. Берничә ел дәвамында күп гасырлык фрескалар яңартыла. Чөнки алар тарихи-мәдәни кыйммәтләргә ия. Без Успенский соборында да булдык, анда изгеләрнең фрескаларын күрдек, шул исәптән ат башлы изге Христофорның сурәтен дә. Моннан берничә ел элек ЮНЕСКО соборны Бөтендөнья мирас объектлары исемлегенә кертә.

Бүген 62 гектар мәйдан биләгән Свияжскта мәдәни мирас булып саналган, дәүләт саклавында булган 39 объект сакланып калынган, шуларның 18е – федераль әһәмияттәге. Биредә соңгы эре объект – 1905нче елда төзелгән “Всех Скорбящих Радость” Изге Ана иконасы исемендәге собор. Аны файдалануга тапшырганнан соң Свияжскның архитектура йөзе формалашу тәмамлана.

Шәһәрчекнең чиста, уңайлы урамнарыннан узганда, бөтен барлыгы белән үткәннәргә чумасың. Биредәге йортлар, биналар борынгылыкны саклап калган. Хәтта сувенир базары да рус халкы колоритын хәтерләтә: халык җырлары яңгырый, сәүдә рәтләрендә агачтан, күннән эшләнгән әйберләр сатыла, рус прәнигеннән дә авыз итәргә мөмкин. Сатучылар туристларга рус патшаларының һәм патшабикәләренең киемнәрен киярге, тирда арбалетлардан атып карарга тәкъдим итәләр. Боларның барысын да күргәч, ихтыярсыздан бөек шагыйрьнең сүзләре искә төшә: “Там русский дух... Там Русью пахнет”. Свияжск буйлап җәяүле экскурсиягә билгеләнгән ике сәгать сизелмичә үтте дә китте. Без җирле кафеда тамак ялгадык, өйдәгеләр өчен кечкенә сувенир әйберләре сатып алдык. Алар безнең һәр адымыбызны статусларда зур игътибар белән күзәтеп бардылар. Шулай итеп сәяхәтебез тәмам, без яңадан Казанга юл алдык.

Идел өстендә тормыш кайный: күпсанлы баржалар, көймәләр, яхталар, метеорлар, теплоходлар йөзә. Ирексездән Нократыбызның шундый чагы искә төшә: анда да бит кайчандыр су транспорты берәзлексез йөзә иде.



"Күңелле сәяхәттә алган тәэсирләр ел буена җитәчәк",– диләр редакция хезмәткәрләре.
Фото шәхси архивтан

# Исеңдә тот һәм котла!


## НУР СИБҮЧЕ КОЯШ СИН!

**Пермь өлкәсенең Чайковск шәһәрендә туып-үсеп, бүгенге көндә Мамадыш шәһәрендә яшәүче ФЛҮРӘ НУРГАЛИ кызы СӘЛӘХЕТДИНОВАга 66 яшь тулган көн уңаеннан.**

Кадерле әниебез! Сине чын күңелебездән туган көнең белән тәбриклибез. Сиңа саулык-сәламәтлек, бәхет-шатлык, озын гомер, күңел тынычлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, балаларыңның, оныкларыңның кадер-хөрмәтен, игелеген күреп, күңел җылысын тоеп яшәргә язсын. Алга таба да бу тормышта безгә терәк һәм кирәк булып, бергә-бергә татулыкта озак яшәвеңне теләп калабыз.



Рәхмәт синең шәфкать тулы йөрәгеңә,
Рәхмәт синең сабыр канат-күңелеңә,
Изгелекләр белән баккан күзләреңә,
Юаныч һәм шатлык биргән сүзләреңә.

**Иң изге теләкләр белән, тормыш иптәшең, улларың – Роберт, Радик, Илдар, Ленар, Айнур, киленнәрең – Ләйсән, Алия, Наталья, Алсу, Екатерина, оныкларың – Сөмбел, Ландыш, Камилә, Радмир, Арслан, Артем, Әмир, Ясминә, Эмилия исеменнән улың Артур.**

## САУЛЫК-СӘЛАМӘТЛЕК ТЕЛИБЕЗ!

**Иске Комазан авылында туып-үсеп, бүгенге көндә Мамадыш шәһәрендә яшәүче ФӘРИДӘ ГАСЫЙМ кызы ШАКИРҖАНОВАның 21нче сентябрьдә 60 яшьлек юбилее.**

Кадерлебез! Сине чын күңелдән матур юбилееӊ белән тәбриклибез. Безнең өчен син һәрчак олы җанлы, киң күңелле, таянычыбыз, ышанычыбыз, киңәшчебез, җылы кояшыбыз, яшәү өлгебез. Бәхет һәм сәламәтлек юлдашың булсын! Якыннарыңның игелеген күреп, мул тормышта, тигезлектә яшәргә язсын Ходай!



Матур көз аенда тугангамы,
Күңелеңдә һәрчак изгелек.
Кылган яхшылыгың кире кайтып,
Күрсәң иде үзең игелек.

**Иң изге теләкләр белән, тормыш иптәшең Сабирҗан, улың Айнур, каенәнең Илнур һәм барлык туганнарың.**


# Парлы тормыш – бәхет ул

Гаилә елы

**Эстония авылларының берсендә бабай белән әби яшәгәннәр. Бабай кечкенә һәм бик тере булган. Ә әби гәүдәгә таза, эшкә әлләни сәләтле түгел, шулай да бик тынгысыз карчык икән.**

Бабай өйдә озаграк утырса, әби: “Ишегалдында берәр эшең юкмыни?” – дип, аны куып чыгара икән. Бабай чыгып китә дә, төрле эш табып, әби чакырмагач, өйгә керергә кыймыйча һаман эшли икән. Әби тәрәзәне ача да: “Өеңә аю мае сөртмәгәннәрдер бит?” – дип, картын өйгә чакыра икән. Бервакыт әби бабайны, аз гына булса да колхозга ярдәмең булыр дип, эшкә куып чыгарган. Бәхетсезлеккә каршы, шул көнне әби ишек бусагасына биле белән егылып, торалмыйча, бабай кайтканчы кичкә кадәр шунда яткан. “Минем хәлемне белешергә өйгә кайтсаң буладыр бит?” – дип карчык картын сүгә. Әби шуннан озак тормаган, үлгән. Бабай үзе генә калган. Ишегалдына чыкса, әби чакырмыймы дип, тәрәзәгә карый, аннан әбине эзләп өйгә керә, ул булмагач, аптырап ишегалдына чыга икән. Шулай шактый ямансулап, каңгырап йөргәннән соң: “Их, әби, тынгысыз булсаң бул, исән генә бул идең”, – ди икән. Бабай шул тынгысыз әбине юксыну сагышыннан атна-ун көн эчендә үлгән, имеш.

Хәзерге көндә мин дә шул бабай кебек хатыным Асияне сагынып, юксынып яшим.

Теләгем шул: тигез тормышның кадерен белегез, тигез яшәргә тырышыгыз! Парлы тормыш – иң зур бәхет. Моның шулай икәнен үзенең тормыш иптәшен югалткан кеше генә чынбарлыгы белән аңлый, тоядыр.

Тормыш иптәшегез һәрвакыт өстәл артында, урын җирдә сезнең белән булсын! Амин!

Мансур **Фазлыев.**



Мәртәбәле кунаклар төрле милли ризыклардан авыз иттеләр.



Сәхнәдә – районыбызның яшь йолдызлары.

# “Кичәгә килүемә алданмадым”

Районыбыз үзешчәннәре узган атнада Казанда отчет концерты белән чыгыш ясады.

Николай **Михайлов**

**Башкалабызның Ленин исемендәге мәдәният үзәгендә узган әлеге чарада һәр чыгыш зур алкышларга күмелде. Районадашларыбызның чыгышларын танылган жюри әгъзалары да, тамашачы да җылы кабул итте.**

Концерт башланганчы мәдәният учагы территориясендә кунакларны, башкалабыз тамашачыларын районыбызда яшәүче төп биш милләт вәкилләре үзләренең сый-нигъмәтләре, җыр-биюләре белән каршы алдылар. Казанлылар татар, рус, керәшен, мари, удмуртлар җырлаганда, биегәндә тик тора алмадылар: районыбызның фольклор коллективларына кушылып җырладылар, биеделәр. Үзәкнең икенче катындагы кул осталарының иҗат җимешләреннән оештырылган күргәзмәдәге һәр экспонатны җентекләп карадылар, кул осталарының мастер-классларында да актив катнаштылар. Күргәзмәләр рәтендә республикабызның танылган шәмаилчесе, якташыбыз Нәҗип Нәккашнең шәмаилләре янында да кешеләр өзелмәде. Республикада гына түгел, халыкара дәрәҗәдә дә танылу алган Нәҗип ага үзен шундый мәдәни чарага чакырганнары өчен районыбыз җитәкчелегенә рәхмәтен белдерде.

–Чакыруны рәхәтләнеп кабул иттем. Бирегә мин Гаилә елы уңаеннан иҗат ителгән шәмаилләремне, шәҗәрәләремне алып килдем. Шуларның дүртесе турыдан-туры Мамадыш районының дүрт авылы белән бәйле: Усали, Түбән Сон, Урта Сон һәм Кече Кирмән. Берничә ел элек берничә иҗат җимешемне композиторлар Яруллиннар, Мамадыш төбәкне өйрәнү музейларына бүләк иткән идем, – диде ул.

Районыбызның оста кулларына бәя бирүчеләр күп булды ул көнне. Шулар арасында Казан федераль университетының Алабуга институты профессоры, ТРның атказанган фән эшлеклесе Дания Сәлимова чара кысаларында күргәннәрдән соклануын яшермәде:

–Бүген мамадышлыларда кунакта булуыма һич тә үкенмим. Сезнең районны күптәннән яратам: анда минем йөзләгән элеккеге студентлар яши, коллегаларым-русистлар белән дә күптәннән элемтәдә торабыз. Аларны үз өлкәләрендә намуслы һәм сәләтле хезмәткәрләр буларак беләм. Бүгенге кичә мин көткәнчә килеп чыкты, алданмадым. Мамадыш менә дигән бәйрәм ясаган: концерт номерлары, халык һөнәрләре һәм сәнгать иҗаты күргәзмәләре (данлыклы Нәҗип Нәккаш дистәләрчә ел инде эшләре белән үзенә җәлеп итеп тора), интерактив чыгышлар, биюләр, менә дигән ризыклар (ялгышмасам, мамадышлылар кунакларны төрле тәм-томнар белән сыйладылар) – болар барысы да югары дәрәҗәдә оештырылган иде. Мине бигрәк тә кул эшләре осталарының иҗат җимешләре сокландырды. Бик матур. Этник нигезнең гармоник палитрасы да сөендерде: кул эшләре, татарларның, керәшеннәрнең, мариларның, русларның, удмуртларның җырлары-биюләре берберләрен тулыландырдылар. Мамадышлы дусларым Нәҗип, Николай, Лидия, Алина, Роза һәм башкалар белән очрашуыма шатмын. Булдырдыгыз! – диде ул.

Концерт башлангачы районыбыз җитәкчесе Вадим Никитин тамашачылар каршында чыгыш ясады. Концерт программасына килгәндә, анда районыбыз үзешчәннәреннән тыш, Татарстанның танылган җырчылары, якташларыбыз Миңгол Галиев, Георгий Ибушев, Гөлнара Габидуллина, Мулланур Габитов та чыгыш ясады. Программада Гаилә елына, ватанпәрвәрлек темасына багышланган җырлар да яңгырады. Урта Кирмәннән Ләйлә һәм Ришат Абдуллиннарның кызлары-кияүләре, уллары, оныклары белән сәхнәдәге чыгышларын да тамашачылар зур алкышларга күмеп каршылады. Концертта катнашкан районыбызның үзешчән сәнгать осталарының барлык җыр-биюләре тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителде.

**Казанның Ленин исемендәге мәдәният үзәгендәге кичәдә РФ Дәүләт Думасы депутаты Анатолий Иванов, Татарстан керәшеннәренең иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Иван Егоров, ТР Дәүләт Советы депутаты Марат Галиев катнаштылар. Мамадышлыларның чыгышларын мәртәбәле жюри бәяләде.**



Чигү остасы Гүзәлия Гобәйдуллинаның эшләрен казанлылар сокланып карады.



Елена һәм Николай Бачковларның чәе үләннәрдән ясалган иде.



Мәдәни үзәк каршындагы мәйданда төрле милләт җырлары яңгырады. Автор фотолары

podpiska.pochta.ru